ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**30.06.2023** **Чистай шәһәре** **№ 396**

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының 2022 елның 23 ноябрендәге
«Муниципаль торак фондында
урнашкан хезмәт торагына наем шартнамәсе
буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗлар
буларак гражданнарны исәпкә алу буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ
регламентын раслау турында»гы 749 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 23 ноябрендәге «Муниципаль торак фондында урнашкан торак урынны наем шартнамәсе буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында»гы 749 номерлы карарын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 23 ноябрендәге 749 номерлы карары белән расланган "Муниципаль торак фондында урнашкан торак урынны наем шартнамәсе буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты"на түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2.5.1 пунктының 9 пунктчасында «(торак урынына һәм җиргә милек турындагы таныклык, аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе, бүләк бирү шартнамәсе һ.б.) сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2 2.6.1 пунктының 11 пунктчасында «Россия Федерациясе пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 3.3.2.1 пунктындагы 11 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан сорауның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында башкарыла.

Бердәм портал тарафыннан дөрес тутырылмаган электрон сорау формасы кыры ачыкланганда гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр аша турыдан туры сорауның электрон формасында хәбәр ителә».

2. Опубликовать настоящее постановление на официальном портале правовой информации Республики Татарстан (pravo.tatarstan.ru) и разместить на официальном сайте Чистопольского муниципального района Республики Татарстан (http://chistopol.tatar.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов